# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

7 апрель, 2026 ел № 1

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым кертү турында» 2025 елның 30 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Лельвиж авылы торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым кертү турында» 2025 елның 30 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар преамбуласындагы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.

Лельвиж авыл җирлеге башлыгы: Э.Ю. Игнатьева